# Уңыш бәйрәме

Алып баручы: Буген бездә матур бәйрәм,

Бүген бездә Уңыш бәйрәме,

Бүген көзге байлык белән

Бизәлгән бүлмәбез дә.

Кадерле балалар, хөрмәтле кунаклар! Бүген без халкыбызның иң гүзәл бәйрәмнәренең берсе – Уңыш бәйрәменә җыелдык. Елның серле фасылында, көн белән төн тигезләшкән вакытта, татар халкы Уңыш бәйрәмен үткәргән. Килгән кунаклар, кадерле балалар, сезне барыгызны да чын күңелдән Уңыш бәйрәме белән котлыйбыз!

Ни арада җәй үтте (Радмир)

Алтын көз килеп җитте

Шатлык тулы бу бәйрәмне

Балалар күптән көтте.

Көз килде дә керде өйгә (Камиль)

Яфраклар йөгерәләр

Ышык эзләп койма капка

Асларына керәләр

Җыр-“Көзге мон”

Көз көннәре килеп җитте (Алмаз)

Хушлашабыз җәй белән

Бөтен җиргә яфраклардан

Алтын келәм җәелгән.

Ямле җәй үтеп китткән (Ясминә)

Алтын сары көз җиткән

Төрле төсле җимешләр

Бакчаны матур иткән

Ишек алдына чыгам

Көзге кәнгә сокланам

Сары, кызгылт, яшел яфрак-

Карыйм да хозурланам.

“Көзге урман” шигыре Кәмилә

Җыр: “В садике садочке” (балаларны утыртабыз)

Залга Көз кызы керә.

Көз кызы: Саумысыз, якын дусларым!

Сезне сагынып килдем мин.

Сезгә аяз көннәр дә,

Байлык та китердем мин.

Мин – Көз кызы,

Көзге байлык кулымда.

Чакырам мин һәммәгезне

Шушы бәйрәм түренә.

Алып баручы: Көз кызы, без син килүгә матур шигырьләр, җырлар өйрәндек. Әйдәле тыңлап карале.

Кошлар китте җылы якка (Ислам)

Үләннә дә саргайды

Көзнең җиткәнен сиздереп

Көннәр дә бик кыскарды

Салкын яңгыр яудырып

Көзгә керәбез инде

Бар уңышны тиз- тиз җыеп

Базга салабыз инде.

Көзнен тагын матурлыгы

Әбиләр чуагында

Балаларның шатланышып

Бакчага баруында

Бик күңелле урамда (Дамир)

Алтын сары бар дөнья

Җил яфраклар биетә

Көз шатлан туй итә

Көзге урман тып-тын булган (Адель)

Агач башы ялангач

Сары яфрак төшә җиргә

Эз генә җил шаяргач

Көз кызы: Бигрәк матур сөйләдегез, әфәрин.

“Зилем-зиләле” уены (1 тапкыр балалар бии, 1- әти-әниләр белән)

(Уңыш бабай керә)

Уңыш бабай: Исәнмесез,балалар, килгән кунаклар! Исәнме, кызым! Сездә милли матур көйләр ишеткәч керергә булдым әле!

Алып баручы: Рәхим ит,Уңыш бабай! Без сине сагынып көттек. Бигрәк зур кәрзинең белән килгәнсең. Балалар, Уңыш бабай, әйдәгез әле, сорап карыйк, Көз безгә нәрсәләр алып килде микән?! Кәрзинеңдәниләр бар?

Уңыш бабай: Бик мул уңыш белән килдем. ( балаларга яшелчәләр муляжларын бирә).Ягез әле балалар кемнәр яшелчәләр турында шигырләр белә?

Алып баручы: Балалар, әйдәгез әле хәзер яшелчәләр белән якыннанырак танышып китик. (Шигырьләр сөйлиләр)

Шигырьләр:

Мин булам кәбестә (Мансур)

Үзем яшькелт төстә

Ашларга төшәм мин

Бәлештә дә пешәм мин

Чөнки мине балалар

Көндә көтеп алалар.

Минем исемем кишер (Әмир)

Теләсән болай пешер

Теләсән ашка тура

Мине яраткан бала

Озын гомерле була

Минем исемем- суган (Нариман)

Мине бик тә мактыйлар

Салатка да турыйлар

Тураганда елыйлар.

Карагыз сез мина (Камилла)

Үзем эре,шома, сөйкемле

Су сипкәнгә үстем мин

Нәфис зифа кызлар шикелле.

Җылы якта тусам да мин ( Радель)

Сездә дә уныш бирәм

Кып-кызыл булып пешәм мин

Тәмләткечләргә керәм

Җир астында җыйнак кына(Нурислам)

Кызарып үсеп ятам

Чөгендерле аш та тәмле

Венегретка да батам

Тыгызланып туп кебек (Радмир)

Үсеп житә бәрәңге

Кырда көлдә пешкәне

Һай! Бигрәк тәмле инде!!

Алып баручы: Уңыш бабай ә без сиңа җыр да әзерләдек.

Җыр: “Кәләпүшем калфагым” (Әмир, Кәмилә)

Уңыш бабай: Менә булдырдыгыз, балалар, рәхмәт сезгә. Әйдәгез әле бергәләп табышмаклар чишеп карыйк:

Үзе кызыл төстә, түгәрәк формада, түтәлдә үсә торган яшелчә (Помидор)

Катлы –катлы яфраклы, яшел төстә, түтәлдә үсә (Кәбестә)

Түтәлдә үсә, яфраклары яшел, үзе бик ачы (Суган)

Озынча, түтәлдә үсә, яшел төстә, эчендә бик күп орлыклары бар (Кыяр)

Алма дисәң дә алалар, нәрсә соң ул, балалар?

Уңыш бабай: Бигрәк акыллы балалар килгәннәр бүгенге бәйрәмгә, бөтен яшелчәләрне дә беләләр, әфәрин!

Балалар минем сезнең белән уйнап аласы килә. «Кашык белән бәрәңге җыю» уен.

Күз кызы: Ә минем әниләрне дә сынап карыйсы килә. (Әниләр дә кашык белән бәрәңге җыю уенын уйныйлар)

Безнең әти-әниләр дә  бик оста уйнаучылар икән.

Алып баручы: Без балалар белән яңа уен өйрәндек шуны күрсәтеп китәсе килә. Яулык белән бию (1 тапкыр- 3 кыз бии М.Ясминә, Света, Мәрьям; 2-С. Камилла, Айгөл, Ф.Ясминә). Әти-әниләргә ошаса-кул чабарсыз.

Уңыш бабай: Сезнең белән бик күңелле, балалар. Балалар, без бик күп яшелчәләр үстерәбез, тәмле – тәмле ризыклар пешерәбез. Ә иң кирәкле, иң тәмле ризык нәрсә ул? (Балалар: Икмәк)

Көз кызы: Дөрес, балалар. Иң тәмле, иң кирәкле ризык ул – икмәк.

Көз көннәре бик күңелле (Әмир)

Бик күп җимешләр пешә.

Помидор, карбыз өлгерә

Алмалар өзелеп төшә.

Арыш бодайлар белән

Колхоз амбары тула

Яхшы эшләгән, уңыш күп

Бар кеше дә бай була.

Көзнең иң олы бүләге – (Мәрьям)

Икмәк тора табында.

Тормышыбыз ямьле булыр,

Икмәк булган чагында.( Мәрьям ипине бирә унышка)

Уңыш бабай: Сезнең белән бик күңелле, балалар  минем сезгә ипинең ничек табынга килүе хакында күрсәтәсе килә.“Икмәк”  турында презентация карау. Менә белдегезме нинди авыр озак юллар үтеп безгә ипи килеп җитә.

Алып баручы: Көзге уңышлар җыелып беткәч, көннәр суыта, көзге яңгырлар ява башлый.

-Апа, безгә артыбыздан (Айгөл)

Шыбыр-шыбыр кем дәшә?

Алып баручы:-Балалар шыбыр-шыбыр кем  эндәшә микән безгә? Беркем дәшми, көзге яңгыр зонтик белән сөйләшә.

Если дождик проливной (Света)

Зонтик я беру с собой

Очень яркий и большой

Желто-красно-голубой

Кто не повстречается

Очень удивляется

Говорит кругом народ:

Вот так чудо зонт идет!

Бию: Зонтиклар белэн бию.

Алып баручы:

Сандугачлар, карлыгачлар,

Очып китте еракка,

Торналар да ялга китте,

Җылы якка, көньякка.

Көз кызы: Монда килгәндә мин күлдә чумып уйнаучы казлар, үрдәкләрне күрдем, алар да җылы якларга очарга әзерләнә иделәр. “Чума үрдәк, чума каз” уены сезгә ошыймы? Бу уенны әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез дә уйнаган. Әйдәгез, без дә уйнап алабыз.

“Чума үрдәк, чума каз” уены.

Көз кызы: Бигрәк матур җырладыгыз, биедегез, Уйнадыгыз, шигырләр сөйләдегез. Барысы өчен рәхмәт сезгә.

Уңыш бабай:Алдагы көннәрдә дә
Телим сезгә уңышлар.
Муллыкта, рәхәт тормышта
Яшәгез, нәни дуслар!

Алып баручы: Бүгенгә без хушлашабыз, бәйрәмне тәмамлыйбыз.

Күңелле дә соң бу көз! Һәрвакыт шундый белемле, зирәк, тырыш, уңган булыгыз.